Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки  авыл җирлеге составына керүче Күки авылы    торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ

2020  елның  23  ноябре                                                                                    № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге составына керүче Күки авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Күки авыл җирлеге составына керүче Күки авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:
    1. Контейнерлар сатып алу.
    2. Күки авылының Яшел-1, Яңа, К.Насыйри урамнарына вак таш сатып алу.
    3. Өлешчә су белән тәэмин итү.(электропогружной насос сатып алу)
    4. Кышкы һәм җәйге  чорда  урамнарны тәртиптә тоту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Күки авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче,
Күки  авыл җирлеге  башлыгы                                                                  А.М.Бәдретдинов

СОВЕТ КУКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ